**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ЕГОРЬЕВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ**
422621 Каип авылы,
Үзәк урамы, 50 нчы йорт,
тел: 3-36-19

**СОВЕТ ЕГОРЬЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЛАИШЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422621 с.Каипы,
ул. Центральная, д.50
тел: 3-36-19

**2023 елның «26» апреле** **18 номер**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Егорьево авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2021 елның 19 октябрендәге 48 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

Лаеш муниципаль районы Егорьево авыл җирлеге Советы «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән карар **кабул итте**:

1) Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Егорьево авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2021 елның 25 октябрендәге 39 номерлы карарына, кушымта нигезендә, үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2) Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

3) Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Башлык-Татарстан Республикасы
Лаеш муниципаль районы Егорьево
авыл җирлеге Советы рәисе
вазыйфаларын башкаручы** **И.Б.Зарипов**

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы
Егорьево авыл җирлеге Советының  2023 елның 26 апреле
18 номерлы  карарына кушымта

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Егорьево авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2021 елның 19 октябрендәге 48 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү

1) **2.2 пунктындагы «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

"Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында»2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы башлыгы (Рәисе) тарафыннан вәкаләтләнгән махсуслаштырылган оешмалар милкендәге җир кишәрлекләренә карата 0,001%;".